СОВЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Октябрьская, д.16, д.Пойкино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Октябрь ур., 16 нче йорт, Пойкино авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-193; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР**
17 сентябрь 2018 ел

**РЕШЕНИЕ**
№6-35

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:

- урам юлларын тигезләү һәм кардан чистарту Пойкино торак пунктында, Келәүш торак пунктында, Тугыз торак пунктында, Сарбаш торак пунктында, Келәүш урманчылыгының торак пунктында, Гурьевка торак пунктында;
- Пойкино торак пунктында Октябрь урамы ягына баручы юлны, Келәүш торак пунктында Завод урамы ягына баручы юлны, Тугыз торак пунктында Совет урамы ягына баручы юлны, Келәүш урманчылыгының торак пунктында Яңа, Бакча урамлары ягына баручы юлларны, Гурьевка торак пунктында Яр буе урамы ягына баручы юлны вак таш җәеп ремонтлау.

2. Ритуаль хезмәтләр күрсәтү һәм күмү урыннарын тотуны оештыру:
- Сарбаш авылы зиратын койма белән әйләндереп алу

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ивановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Иванов Б.В.